ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

25 апрель 2018ел

**КАРАР**

№ 2307

Башкарма комитетның «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасы буенча исәпкә кую һәм торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 20 сентябрендәге 5735 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

«2014-2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 30 апрелендәге 289 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 30 маендагы 322 нче карары, шәһәр Уставының 42 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасы буенча исәпкә кую һәм торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 20 сентябрендәге 5735 нче карарына (Башкарма комитетның 2016 елның 27 июнендәге 3276 нчы карары редакциясендә), кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 25 апрелендәге
2307 нче карарына
кушымта

«Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү»
программасы буенча исәпкә кую һәм торак сатып алуга (төзүгә)
социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасы буенча исәпкә кую, ел саен кабаттан теркәү һәм торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт (алга таба – муниципаль хезмәт) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт алучылар: физик затлар (алга таба – гариза бирүче).

1.3. Муниципаль хезмәт Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә (алга таба – Башкарма комитет).

Муниципаль хезмәтне үтәүче – Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе (алга таба – Идарә); Башкарма комитетның Комсомол, Үзәк, Автозавод районнары Хакимиятләре (алга таба – район Хакимиятләре).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашкан урыны: Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт.

Идарәнең урнашкан урыны: Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 217 кабинет.

Район Хакимиятләре урнашкан урын:

Комсомол районы – ГЭС, 8/7 нче йорт, 5, 6 кабинетлар.

Үзәк районы – Яңа шәһәр, 3/08 нче йорт, 103 кабинет.

Автозавод районы – Яңа шәһәр, 49/09 нчы йорт, 101 кабинет.

Эш графигы:

дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр;

шимбә һәм якшәмбе – ял көннәре.

Төшке аш вакыты 12.00 дән 13.00 сәгатькә кадәр.

Белешмә өчен телефоннар:

Идарә – 30-56-53;

Комсомол районы – 70-45-46;

Үзәк районы – 47-55-72;

Автозавод районы – 32-98-39.

Керү шәхесне таныклаучы документлар буенча.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге рәсми сайтының адресы: www.nabchelny.ru (алга таба – «Интернет» челтәре).

1.3.3. Муниципаль хезмәт турындагы мәгълүматны түбәндәге ысуллар аша алырга мөмкин:

1) районнар Хакимиятендә мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен куелган, муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүмат булган мәгълүматлар стенды аша;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайты аша (www.nabchelny.ru);

3) Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

4) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

5) районнар Хакимиятендә:

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

язма рәвештә мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә) – почта аша кәгазь йорткечтә, электрон почта аша электрон рәвештә.

1.3.4. Муниципаль хезмәтләр күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат районнар Хакимияте белгечләре тарафыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм районнар Хакимиятендә гариза бирүчеләр белән эшләү өчен куелган мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәтләр күрсәтү түбәндәге нигездә гамәлгә ашырыла:

1) Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ санлы Торак кодексы (Собрание законодательства РФ, 03.01.2005, №1 (часть 1, ст. 14) (алга таба – РФ Торак кодексы);

2) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон (Собрание законодательства РФ, 02.08.2010, №31, ст. 4179) (алга таба – 210-ФЗ санлы Федераль закон);

3) Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт белән идарә итү системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 нче указы («Российская газета», 09.05.2012 ел, №102, «Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы» (www.pravo.gov.ru), 07.05.2012, Собрание законодательства Российской Федерации, 07.05.2012, №19, ст. 2338) (алга таба – РФ Президентының 601 нче Указы);

4) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм комфортлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыру турында» 2010 елның 17 декабрендәге

1050 нче карары (Собрание законодательства РФ, 31.01.2011, №5, ст. 739) (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 1050 нче карары);

5) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 30 апрелендәге 289 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыелмасы, 20.05.2014, № 37, ст. 1160) (алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 289 нчы карары);

6) «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын тормышка ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләре, «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасына 3 нче кушымта (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыелмасы, 20.05.2014, №37, ст. 1160) (алга таба – Кагыйдәләр);

7) Шәһәр Советының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 нче карары белән кабул ителгән «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы («Челнинские известия», 30.12.2005, №249-250) (алга таба – Устав);

8) Шәһәр Советының «Торак бүлмә бирү нормасын һәм исәпкә кую нормасын билгеләү турында» 2006 елның 10 мартындагы 9/7 нче карары («Челнинские известия», 01.04.2006, №57-59);

9) Башкарма комитетның 2007 елның 16 июлендәге 754 нче боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре;

10) Башкарма комитетның «Гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча федераль һәм республика ярдәмче программаларын Яр Чаллы шәһәре территориясендә тормышка ашыруны тәэмин итү буенча торак комиссиясе төзү турында» гы 2007 елның 6 сентябрендәге 3255 нче карары;

11) Башкарма комитетның 2014 елның 11 мартындагы 147-р санлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның хезмәт регламенты (алга таба – Хезмәт регламенты);

12) Башкарма комитетның «2016-2020 елларга Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын раслау турында» 2016 елның 14 мартындагы 1078 нче карары («Челнинские известия», 18.03.2016, №19) (алга таба – Башкарма комитетның 1078 нче карары).

1.5. Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

Яшь гаиләләр – яшь гаиләләр, шул исәптән бер яшь ата-анадан һәм бер һәм аннан да күбрәк балалардан торган, түбәндәге шартларга туры килгән тулы булмаган яшь гаилә:

а) Программаның дәүләт заказчысы яшь гаиләне Программада катнашучы яшь гаиләне планлаштырылган елда социаль түләү алуга дәгъва кылучылар исемлегенә кабул иткән көнгә ир белән хатынның яисә тулы булмаган гаиләдә бер ата-ананың яше 35 яшьтән артмаска тиеш;

б) Кагыйдәләрнең 5 пункты нигезендә гаиләне торак шартларын яхшыртуга мохтаж дип тану;

в) яшь гаиләнең барлык әгъзаларын, балаларын да кертеп, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәү урыны буенча теркәү;

г) торакның исәп-хисап (уртача) бәясенең бирелә торган социаль түләү күләменнән арткан өлешен түләү өчен гаиләнең җитәрлек керемнәре яисә банкка акчалары булу;

социаль түләү – Россия Федерациясе бюджеты һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына күрсәтелә торган социаль ярдәм чарасы.

Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запрос аңлашыла (210-ФЗ санлы Федераль законның 2 маддәсенең 2 пункты). Гариза Регламентка 1, 2, 3 нче кушымталарда каралган форма буенча тутырыла.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр исемлеге | Стандартка таләпләрнең эчтәлеге | Хезмәтне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме | «2016-2020 елларга Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасы буенча исәпкә кую, ел саен кабаттан теркәү һәм торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү | РФ Торак кодексының 2 маддәсенең 2 пункты; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 нче карары; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 нчы карары; Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 14 мартындагы 1078 нче карары |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче башкарма хакимият органының исеме | Районнар Хакимияте | Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 14 мартындагы 1078 нче карары |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Яр Чаллы шәһәре территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча, планлаштырылган елда торакның исәп-хисап (уртача) бәясенең бирелә торган социаль түләү күләменнән арткан өлешен түләү өчен гаиләнең җитәрлек керемнәре яисә башка акчалары булган яшь гаиләләрне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак тану | Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 14 мартындагы 1078 нче карары |

| | | |
|---|---|---|
| | турында, программаны тормышка ашыруда катнашу максатында федераль һәм республика программаларын тәэмин итү буенча торак комиссиясе (алга таба – торак комиссиясе) карары.<br>Ел саен 1 майдан 1 июньгә кадәрге чорда торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар сыйфатында программада катнашу өчен исәптә торучы яшь гаиләнең торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыгын һәм түләү сәләтлелеген тикшерү үткәрә.<br>Яшь гаиләләргә торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында карар. | |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы | Исәпкә кую һәм гаризаны теркәгәннән вакыттан башлап 30 көн эчендә – ел саен кабат теркәү<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү срогына түбәндәгеләр керми:<br>- социаль түләү алуга чират җитүен көткән вакыт. Торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү чират тәртибендә – гариза биргән вакыттан башлап 5 көн эчендә. | Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 14 мартындагы 1078 нче карары |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге | 1) Яшь гаиләне торак шартларын яхшыртуга мохтаж дип тану (Регламентка 1 нче кушымта) турында ике нөсхәдә гариза (бер нөсхәсе, гаризаны кабул итү датасы һәм аңа беркетелгән документлар күрсәтелеп, гариза бирүчегә кире кайтарып бирелә);<br>2) һәр гаилә әгъзасының шәхесен таныклаучы документлар күчермәләре;<br>3) никахлашу турында таныклык күчермәсе (тулы булмаган гаиләгә кагылмый); | Кагыйдәләрнең 15 пункты;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 нче карары;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 нчы карары; |

| | | |
|---|---|---|
| | 4) вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (гариза бирүче исеменнән аның вәкиле эш иткәндә);<br>5) яшь гаиләләрне – планлаштырылган елда (Регламентка 2 нче кушымта) социаль түләүләр алуга дәгъва кылучылар исемлегенә кертү турында ике нөсхәдәге гариза һәм аңа торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыкны, түләү сәләтлелеген дәлилләү өчен кирәкле документлар теркәлергә тиеш (бер нөсхәсе, гаризаны кабул итү датасы һәм аңа беркетелгән документлар күрсәтелеп, гариза бирүчегә кире кайтарып бирелә);<br>6) яшь гаиләнең балигъ булган әгъзаларының «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законның 9 маддәсе нигезендә яшь гаилә әгъзалары турындагы шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә язмача ризалыгы;<br>7) гаиләнең торакның исәп-хисап (уртача) бәясенең бирелә торган социаль түләү күләменнән арткан өлешен түләү өчен кредит алу мөмкинлеге бирә торган җитәрлек керемнәре яисә башка акчалары булуын дәлилләүче документ;<br>8) торакның гомуми мәйданы, бирелү датасы күрсәтелгән финанс-шәхси счеты (оригинал);<br>9) йорт кенәгәсеннән бирелү датасы күрсәтелгән өземтә (оригинал);<br>10) теркәлү урыны буенча биләгән торак мәйданына хокук бирүче, шулай ук соңгы 5 елда милектә саналган башка торак урыннарына хокук бирә торган документларның күчермәләре (социаль наем килешүе, хосусыйлаштыру килешүе, сату-алу килешүе, бүләк | Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 14 мартындагы 1078 нче карары |

| | | |
|---|---|---|
| | итү килешүе, хокукны теркәү турындагы таныклык һәм башкалар), шәхси торак төзелеше объектларында яшәүчеләр өчен – әлеге объектның техник паспорты;<br>11) элекке теркәлү урынының адресы, теркәлү датасы, теркәүдән төшү датасы, торакның гомуми мәйданы, соңгы биш елда яшәүчеләрнең саны күрсәтелгән архив белешмәләре;<br>12) Техник инвентаризацияләү бюросыннан, 2000 елның 1 гыйнварына булган мәгълүматлар буенча, теркәлгән күчемсез милекнең булуы (булмавы) турында гражданның, барлык яшь гаилә әгъзаларының барлык капиталь төзелеш объектларына хокукы булуын (булмавын) дәлилләүче белешмә, шул исәптән элекке яшәү урыныннан да;<br>13) барлык яшь гаилә әгъзаларының ИНН күчермәләре;<br>14) барлык яшь гаилә әгъзаларының иминият таныклыклары күчермәләре;<br>15) гражданның эш урыныннан аның вазыйфасы күрсәтелгән, оешма житәкчесе яки аның урынбасары имзалаган һәм оешманың мөһере сугылган оешма реквизитлары белән белешмә – барлык яшь гаилә әгъзаларына да;<br>16) хезмәт кенәгәсе күчермәсе – барлык яшь гаилә әгъзаларына да;<br>17) алдагы һәм агымдагы еллар өчен хезмәт хакы турында белешмә (2-НДФЛ формасы буенча, яшәү адресын күрсәтеп) – барлык яшь гаилә әгъзаларына да; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 18) стипендия (студентлар өчен), пособиеләр, пенсияләр, алиментлар (булганда) алу турында белешмәләр;<br>19) яшь гаиләнең кертеме булуын дәлилләүче документлар (яшь гаиләнең берәр әгъзасына рәсмиләштерелгән банк кертеме булуын раслаучы банк документы күчермәсе, яки яшь гаилә әгъзаларының тупланма счетларыннан өземтә), һәм (яки) ир белән хатынга яисә аларның берсенә кредитның максималь күләмен күрсәтеп, кредит (заем) бирү мөмкинлеге турында кредит оешмасы документы;<br>20) салым инспекциясе билгесе белән (эшмәкәрләр өчен) алдагы календарь елы һәм агымдагы календарь елының хисап чоры өчен декларация яки керемгә салым түләүгә күчкән эшмәкәрләр өчен керемгә салым түләү турында таныклык (соңгы алты айга).<br>Социаль түләүләрне бурычның төп суммасын каплауга һәм торак кредитлары буенча процентларны түләүгә, шул исәптән торак сатып алуга яки торак йорт төзүгә ипотека, яки торак заемнарына файдалану максатында, башка процентлардан, штрафлардан, әлеге кредитлар яки заемнар буенча йөкләмәләр үтәүне кичектергән өчен комиссия һәм пенялардан тыш, программада катнашу өчен яшь гаилә яшәү урыны буенча районнар Хакимиятенә түбәндәге документларны тапшыра:<br>а) һәр гаилә әгъзасының шәхесен таныклаучы документлар күчермәләре; | |

| | | |
|---|---|---|
| | б) никахлашу турында таныклык күчермәсе (тулы булмаган гаиләгә кагылмый);<br>в) яшь гаиләләрне – планлаштырылган елда (Регламентка 2 нче кушымта) социаль түләү алуга дәгъва кылучылар исемлегенә кертү турында ике нөсхәдәге гариза һәм аңа торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыкны, түләү сәләтлелеген дәлилләү өчен кирәкле документлар теркәлергә тиеш (бер нөсхәсе, гаризаны кабул итү датасы һәм аңа беркетелгән документлар күрсәтелеп, гариза бирүчегә кире кайтарып бирелә);<br>г) кредит килешүе (заем килешүе) күчермәсе;<br>д) төп бурычтан калган сумма һәм торак ипотекасы кредитыннан (заемнан) файдаланган өчен процентлар түләүдәге әҗәт суммасы турында кредит (заем) бирүчедән алынган белешмә. | |
| 2.6. Муниципаль хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге | Ведомствоара үзара эшчәнлек кысаларында түбәндәгеләр алына:<br>1) күчемсез милеккә һәм аның белән сату-алу эшләренә хокукларның Бердәм дәүләт реестрыннан аерым затның булган (булдырган) күчемсез милек объектларына хокуклары турында өземтә (барлык яшь гаилә әгъзаларына да);<br>2) күчемсез милеккә һәм аның белән сату-алу эшләренә хокукларның Бердәм дәүләт реестрыннан хокукларның күчемсез милек объектына күчүе турында өземтә. | 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен килешенү (муниципаль хезмәтне күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла) таләп итеlә торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | Килешү таләп ителми. | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) Документлар тиешле булмаган зат тарафыннан тапшырылу;<br>2) тапшырылган документлар Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәү;<br>3) гариза текстын уку мөмкин булмау;<br>4) документларны тиешле булмаган органга тапшыру. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 нчы карары;<br>Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 14 мартындагы 1078 нче карары |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигез каралмаган.<br>Кире кагу өчен нигез:<br>а) яшь гаилә Регламентның 1.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәү, шул исәптән ир белән хатынның берсе яки һәркайсы яисә тулы булмаган гаиләдә бер ата-ана 35 яшьтән узып китү;<br>б) Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау яки тулы булмаган күләмдә тапшыру;<br>в) гариза бирүче тапшырган документларда дөрес | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 нчы карары;<br>Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 14 мартындагы 1078 нче карары |

| | | |
|---|---|---|
| | булмаган мәгълүмат ачыклану;<br>г) социаль түләүне яки федераль бюджет хисабына дәүләт ярдәменең башка формаларын файдаланып торак шартларын яхшыртуга хокукның яшь гаилә тарафыннан элегрәк гамәлгә ашырылган булуы. | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы алу тәртибе, күләме һәм муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган башка түләүнең нигезләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә. | 210-ФЗ санлы Федераль законның 8 маддәсе 1 бүлеге |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен түләү алуның тәртибе, күләме һәм нигезлелеге, андый түләү күләменең исәп-хисап методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Чират булганда, муниципаль хезмәт алуга гариза бирү – 15 минуттан да артык түгел.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратта көтү срогы 30 минуттан артырга тиеш түгел. | Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 601 нче Указы |
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы | Гариза кергән вакыттан башлап бер көн эчендә. | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү, | Муниципаль хезмәтләр күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар тутыру өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары | |

| | | |
|---|---|---|
| аларның күтеп тору урыннарына, шул исәптән күрсәтелгән объектларны Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә тәэмин итү, андый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедия мәгълүматын урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә таләпләр | белән җиһазландырылган бина һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидларга муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу, аның чикләрендә хәрәкәтләнү).<br>Муниципаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедия мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән мөмкинлекләре чикле инвалидларны да истә тотып. | |
| 2.15. Муниципаль хезмәтнең һәркем алырлык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре | Муниципаль хезмәтнең һәркем алырлык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>1) документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;<br>2) муниципаль хезмәт алуның срогын үтәү;<br>3) Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан Регламентны бозу прецедентлары (дәлилле шикаятьләр) булу.<br>Муниципаль хезмәтләрне дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрдә (алга таба – Күпфункцияле үзәк) күрсәткәндә консультация бирүне, документлар кабул итү һәм бирүне Күпфункцияле үзәк белгече гамәлгә ашыра. | Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 601 нче Указы |
| 2.16. Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтүнең үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы консультацияне электрон рәвештә Интернет-кабул итүе яки Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин. Әгәр законда муниципаль хезмәт күрсәтү турында | |

| | | |
|---|---|---|
| | электрон рәвештә гариза бирү каралган булса, ул очракта гариза Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/) яки Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша (http:// www.gosuslugi.ru/) бирелә. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау.

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара запросларны формалаштыру һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органга җибәрү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы Регламентка 5 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү.

3.2.1. Гариза бирүче, муниципаль хезмәттән файдалану тәртибе турындагы консультацияләрне телефон һәм (яки) электрон почта аша алу өчен, яшәү урынындагы Хакимияткә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Район Хакимияте белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәттән файдалануның составы, тапшырыла торган документларның формасы һәм башка мәсьәләләр буенча һәм кирәк булганда, гариза бланкын тутыруга ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: муниципаль хезмәттән файдалануның составы, тапшырыла торган документларның формасы һәм исәпкә кую һәм социаль түләүләр алуга, муниципаль хезмәттән файдалануга хокук турында таныклык бирү буенча башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән яки ышанычлы зат аша муниципаль хезмәт күрсәтү турында язмача рәвештә гариза бирә һәм Регламентның 2.5 пункты нигезендә район Хакимиятенә документлар тапшыра.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы электрон рәвештәге гариза район Хакимиятенә электрон почта яки Интернет-кабул итүе аша җибәрелә. Электрон рәвештә кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.3.2. Район Хакимиятенең гаризалар кабул итүне алып баручы белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гариза бирүченең шәхесен ачыклый;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерә (ышаныч язуы белән эш иткән очракта);

Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булуын тикшерә;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә.

Кимчелекләр булмаган очракта, район Хакимияте белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм махсус журналда терки;

гариза бирүчегә гаризаның документларны кабул итү датасы, теркәгәндә бирелгән саны, муниципаль хезмәт күрсәтүне үтәү датасы һәм вакыты турында билге куелган бер нөсхәсен бирә.

Документлар кабул итүне кире кагу өчен Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булган очракта, район Хакимиятенең гаризалар кабул итүне алып баручы белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен тоткарлыклар булуы турында хәбәр итә һәм документлар кабул итүне кире кагу өчен ачыкланган сәбәпләрне язмача аңлатып, документларын кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар 15 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза һәм гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.4. Ведомствоара запросларны формалаштыру һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органга җибәрү.

3.4.1. Район Хакимияте белгече ведомствоара электрон эшчәнлек системасы аша электрон рәвештә күчемсез милеккә һәм аның белән сату-алу эшләренә хокукларның Бердәм дәүләт реестрыннан асрым затның булган (булдырган) күчемсез милек объектларына хокуклары турында өземтә (һәр гаилә әгъзасына) бирү хакында запрос җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән запрос.

3.4.2. Мәгълүмат бирүченең белгечләре, ведомствоара электрон эшчәнлек системасы аша кергән запрос нигезендә, соралган документларны (мәгълүматны) бирәләр яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның һәм (яки) мәгълүматның булмавы турында хәбәр җибәрәләр (алга таба – кире кагу турында хәбәр итү).

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар документ һәм мәгълүмат бирүче орган яки оешмага ведомствоара запрос кергән көннән башлап биш көн эчендә гамәлгә ашырыла, әгәр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең федераль законнарында, хокукый актларында һәм Татарстан Республикасының федераль законнар нигезендә кабул ителгән норматив хокукый актларында ведомствоара запроска җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары билгеләнмәгән булса.

Процедураларның нәтиҗәсе: район Хакимиятенә җибәрелгән документлар (мәгълүматлар) яисә кире кагу турында хәбәр итү.

3.5. Эшне торак комиссиясендә карауга әзерләү.

3.5.1 Район Хакимияте белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

- тапшырылган документлардагы мәгълүматларның дөреслеген тикшерә;

- гаиләнең исәпкә алу делосын рәсмиләштерә;

- Регламентның 2.9 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен нигезләр булуын тикшерә. Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен нигезләр булган очракта, район Хакимияте белгече муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында хат әзерли, аны район Хакимияте Башлыгы белән килештерә һәм гариза бирүчегә җибәрә, күчермәсен исәпкә алу делосына теркәп куя;

- гаиләнең исәп эше делосын карау өчен торак комиссиясенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар запросларга җаваплар кергән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гаиләнең карау өчен торак комиссиясенә җибәрелгән исәпкә алу делосы яисә муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында гариза бирүчегә җибәрелгән хат.

3.5.2. Торак комиссиясе исәпкә алу делосын карый һәм субсидия алырга хокукы булган яшь гаиләләрне исемлеккә кертү яисә муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында карар кабул итә. Торак комиссиясенең карары беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә һәм Идарә белгеченә җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар исәпкә алу делосы кергән вакыттан башлап унбиш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: социаль түләү алуга таныклык алу өчен исәпкә кую турында (яисә куюны кире кагу) торак комиссиясе карары.

3.6. Муниципаль хезмәтнең нәтиҗәсен әзерләү.

3.6.1. Идарә белгече торак комиссиясе карары нигезендә субсидия алуга яшь гаиләләрнең исемлеген (алга таба – исемлек) формалаштыра һәм аны Башкарма комитет Җитәкчесенә раслауга җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитет Җитәкчесенә раслауга җибәрелгән исемлек.

3.6.2. Башкарма комитет Җитәкчесе исемлекне раслый һәм Идарә белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: расланган исемлекне Идарә белгеченә җибәрү.

3.6.3. Идарә белгече, расланган исемлекне алып, Татарстан Республикасы Яшьләр белән эшләү һәм спорт министрлыгына (алга таба – Программаның заказчысы) планлаштырылган елда программаны тормышка ашыру кысаларында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыгын дәлилләгән, керемнәре яисә торакның исәп-хисап (уртача) бәясенең бирелә торган социаль түләү күләменнән арткан өлешен түләү өчен җитәрлек керемнәре яки банк акчалары булган (кабат теркәү үткәннәрне) һәм язма рәвештә

тиешле елда социаль түләү алуга теләк белдергән), Регламентка 3 кушымтада каралган гариза буенча яшь гаиләләр исемлеген Программаның дәүләт заказчысы тарафыннан күрсәтелгән срокларда җибәрә.

Планлаштырылган елда социаль түләүләр алуга дәгъва кылучы яшь гаиләләрнең исемлек формасы Программаның заказчысы тарафыннан билгеләнә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Программа заказчысына җибәрелгән исемлек.

3.7. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.7.1. Идарә белгече Программа заказчысыннан кергән мәгълүматлар нигезендә субсидия алуга дәгъва кылган яшь гаиләләр исемлегендә билгеләнгән чират тәртибендә субсидия алуга таныклык рәсмиләштерә.

